ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Вөждан ирege турында һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Вөждан ирege турында һәм дини берләшмәләр турында” 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:
а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“үз дәвамчыларыңны дингә өйрәтү һәм дини тәрбияләү;”;
б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Дини берләшмәләр миссионерлык эшчәнлеген “Вөждан ирege турында һәм дини берләшмәләр турында” 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыралар.”;

2) 15 статьяның 3 пунктында “шөгыльләнә алмый,” сүзләреннән соң “аның исеменнән миссионерлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла алмый һәм” сүзләрен өстәргә;

3) 21 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Дини оешмалар чыгара торган, шулай ук аның исеменнән миссионерлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру кысаларында таратыла торган әдәбият, басма, аудио- һәм видеоматериаллар әлеге дини оешманың тулы рәсми исеме белән тамгаланырга тиеш.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 17 ноябре
№ 85-ТРЗ